“Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесе

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы
“Азнакай шәһәре балалар иҗат үзәге”

Педагогик совет утырышында
каралды һәм кабул ителде
Беркетмә № 1
“07” 09 2022ел.

ГАМӘЛГӘ КЕРТЕЛДЕ
07.09.2022 приказ № 126
Директор: ӨББМБО “Азнакай шәһәре БИҮ”
_________ Р.М Хасанова
“07” 09. 2022 ел.

# " Туган як серләре"өстәмә гомуми белем бирү, гомумүсеш программасы

Юнәлеш: туристлык – туган төбәкне өйрәнү
Укучыларның яше: 12 -15 яшьлекләр өчен
Гамәлгә ашыру вакыты: 2 ел (360 сәгать)

Автор-төзүче:
Саргузина Гүзәл Рәсим кызы,
өстәмә белем бирү педагогы

Азнакай шәһәре, 2019

Эчтәлек

**1.** Аңлатма язуы ______________________________________3 бит.
**2.** Уку-укыту тематик планы_________________________ 7 бит.
**3.** Программаның эчтәлеге _________________________27 бит.
**4.** Планлаштырылган нәтиҗәләр ______________________34 бит.
**5.** Программаны тормышка ашыруның оештыру-педагогик шартлары ________________________35 бит.
**6.** Аттестацияләү формалары / контроль һәм бәяләү материаллары ______________________________________ 37 бит.
**7.** Әдәбият исемлеге ____________________________________38 бит.

## 1 нче бүлек
## Аңлатма язуы

“Туган як серләре” өстәмә гомуми белем бирү**, гомумүсеш программасы** түбәндәгеләрне норматив-хокукый документларга нигезләнеп төзелде :

1. "Россия Федерациясендә Мәгариф турында" 29.12.2012 чыккан № 273 - ФЗ Федераль законы;
2. Балаларга өстәмә белем бирү үсеш концепциясе (4 нче сентябрь 2014 нче елда чыккан, № 1726-р РФ Хөкүмәте карары );
3. “Мәгариф” милли проекты кысаларында “Һәр баланың уңышы” федераль проекты. РФ Президенты каршындагы Стратегик үсеш һәм милли проектлар советы президиумның 2018 елның 3 сентябрендә 10 номерлы утырыш беркетмәсе белән расланган.
4. Россия Мәгариф министрлыгының “Балаларга өстәмә белем бирүнең төбәк системаларын үстерүнең максатчан моделен раслау турында” 2009 елның 3 сентябрендәге 467 номерлы боерыгы.

**5.** Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгының “Өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында” 2018 елның 9 ноябрендәге 196 номерлы боерык

**6.** РФ Мәгариф һәм фән Министрлыгының “Белем бирү эшчәнлеген, электрон белем бирүне, белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда дистанцион белем бирү технологияләрен гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан куллану тәртибен раслау турында” 2017 елның 23 августындагы 816 номерлы боерык»

**7.** "СанПиН 2.4.4.3172 -14 "Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында эш оештыру төзелеше, эчтәлеге һәм режимына куела торган санитария-эпидемиология таләпләре " РФ дәүләт баш санитария табибының 04.07.2014 чыккан 41 нче номерлы карары

## Программаның төп характеристика комплексы

Программаның юнәлеше – **туристлык – туган төбәкне өйрәнү**

Әлеге программа укучыларда туган як тарихы, мәдәнияте, әдәбият - сәнгате буенча белемнәр формалаштырырга мөмкинлек бирә. Туган як тарихын өйрәнү халыкның иҗади көчен, гореф-гадәтләрен һәм игелекле традицияләрен тулысынча өйрәнүне күздә тота.Укучылар үзләре яши торган төбәкнең традицияләрен, халкын, тарихын, мәдәниятен, табигатен, аның үзенчәлекләрен эзләнү – тикшеренү эшләре аша ачыклыйлар; үз халкының рухи байлыгын өйрәнеп, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертүгә омтылалар; туган як белән кызыксынулары аша аңа мәхәббәт, туган ягыбыздан чыккан әдипләр, күренекле кешеләр белән горурлану хисләре тәрбияләнә.

<u>“Туган як серләре” өйрәнү түгәрәгендә шөгыльләнгән бала:</u>

- үз гаиләсе тарихына хөрмәт белән карый, горурлану хисләре кичерә;
- мөстәкыйль рәвештә ачышлар ясый;

- материал җыя, гомумиләштерә, мәктәп музееН тулыландыра;
- эзләнү эше алып бара, материалны анализлый, системалаштыра, гомумиләштереп, нәтиҗәләр ясый;
- уеннар вакытында өйрәнгән материалны ныгыта;
- туган як әдәбияты, тарихы буенча белемнәрен арттыра;
- фәнни-тикшеренү эшләренә өйрәнә;
- үз – үзендә патриотизм, туган якка мәхәббәт хисе тәрбияли;
- туган төбәгенең тарихына, әдәбиятына, сәнгатенә бәйле күренекле шәхесләре белән горурлана.

**Программаның актуальлеге:** Бүгенге җәмгыятьтә укытучы алдында гаять зур бурычлар тора. Конкуренциягә сәләтле, заман таләпләреннән чыгып эш итә белә торган, рухи һәм физик яктан камил шәхес тәрбияләү – иң төп максатыбыз.Ә ул үз чиратында , туган телебезне яратучы, үз милләтенең мәдәниятен, иң күркәм йолаларын, гореф-гадәтләрен, тарихын хөрмәт итүче булырга тиеш. Зыялылык, ватанпәрвәрлек кебек сыйфатлар үзеңнең туган ягыңны, аның тарихын, кешеләрен яхшы белгәндә генә формалаша ала. Туган якны яратырга өйрәтү, туган якка мәхәббәт тәрбияләү, туган як тарихын өйрәнү - патриотик тәрбия бирүнең иң отышлы ысуллары. Туган як тарихы ул - шунда яшәгән кешеләр тарихы. Кешенең тарихта тамырлары гаиләсенең традицияләрендә, халкының, туган ягының үткәнендә. Туган як тарихын өйрәнү укучыларга үз төбәкләрендә яшәгән кешеләр турында күбрәк белергә, якыннан танышырга мөмкинлек бирә.

Патриотик тәрбия бирүдә тагын мөһим чараларның берсе - музейлардагы хәзинәне - тарихи экспонатларны, халкыбызның рухи һәм матди культурасын, бүгенгесен һәм узганын чагылдыручы кыйммәтле материалларны куллану. Укучыларда туган илгә мәхәббәт, халкыбызның үткәндәге истәлекләрен хөрмәт итү, хәзерге казанышларына ихтирам һәм горурлык хисләре, милли аң тәрбияләүдә, укучыларга патриотик тәрбия бирүдә мәктәп музейлары зур әһәмияткә ия. Музей шулай ук туган якның , туган авылның , туган мәктәпнең тарихын өйрәнү, аны буыннан буынга саклап калдыруда һәм укыту-тәрбия эшендә зур ярдәмче. Музейда үткәрелгән очрашулар, экскурсия, дәресләр , туган якка кагылышлы җирле материалларны өйрәтү аша балалар күңеленә патриотизм орлыклары салына. Мәктәптә үткәрелгән әдәби кичәләр - укучыларга чын-чынлап илһам чыганагы. Балаларга алдагы буыннарның бай тормыш тәҗрибәсен өйрәтү,тарихы, гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру кебек максатларга ирешү өчен музей материаллары - чиксез бай хәзинә.

Туган як тарихын өйрәнү халыкның иҗади көчен, гореф-гадәтләрен һәм игелекле традицияләрен тулысынча өйрәнүне күздә тота. Укучы үзе яши торган төбәкнең традицияләрен, халкын, тарихын, мәдәниятен, табигатен, аның үзенчәлекләрен аеруча яхшы белергә тиеш.

Түгәрәк эшчәнлеге укучыларны халкыбызның рухи - әхлакый идеалларына китерергә, аларда сөйләм культурасы формалаштырырга, иҗади сәләтен үстерергә, мөстәкыйль уйларга һәм эшләргә омтылышын канәгатьләндерү

юнәлешендә дә эш алып бара. Түгәрәктә танып - белү эшчәнлеге аралашу формасында оештырыла. Укучылар түгәрәктә газета - журналлар басу технологиясе, газета әсәрләре иҗат итүнең баскычлары (тема табу, фактлар туплау, әңгәмә үткәрү, текст төзү, ритм, рифма һ.б.), журналистика жанрлары турында да мәгълүмат алалар. Үзләре газета - журналлар өчен шигырьләр, хикәяләр, мәкаләләр иҗат итәләр, үзләре язган шигырьләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнәләр.

Программаның актуальлеге укучыларда туган як тарихы, мәдәнияте,әдәбият - сәнгате буенча белемнәр формалаштыру кирәклеге һәм куелган максат, бурычлардан чыгып билгеләнә.

**Программаның аерылып торучы үзенчәлекләре:** тарихны сөйләп кенә бала күңеленә сеңдереп булмый.Бала эшчәнлеккә үзе катнашканда гына , үз күзләре белән күреп, үз куллары белән тотып караганда гына үзе өчен ачышлар ясый һәм белмәгәннәрен бүтәннәргә җиткерә ала. Эзләнү – тикшеренү эшләре аша, калган укучыларга да туган ягыбызның тарихын җиткерү, халкыбызның мәдәнияте, әдәбияты, сәнгате белән кызыксындыруга ирешү.

**Программаның адресаты:** 12-16 яшьлек укучылар.

**Программаны үзләштерү вакыты, дәресләр үткәрү режимы, периодлылыгы, дәвамлылыгы:** "Туган як серләре" өстәмә белем бирү программасы 3 елга исәпләнә. Уку планында атнага 2 тапкыр 2 сәг. Барлыгы 144 сәгать беренче уку елында, атнага 3 тапкыр 2 сәг. - 216 сәгать икенче уку елында, атнага 3сәг.-216 сәг өченче уку елында атнага 3 сәгать.

**Дәресләрне үткәрү формалары:** практик, мөстәкыйль һәм иҗади эшләр, интеллектуаль уеннар, эзләнү – тикшеренү эшләре, экскурсияләр, эшлекле уен, әдәби кичәләр.

Укучыларда кызыксыну уяту өчен һәр дәрестә иҗадилык һәм эзләнү элементларын кертү.

Теоретик һәм практик эшләрне чиратлаштыру.

**Оештыру үзенчәлекләре:** төрле яшьтәге укучыларның даими группасы.

**"Туган як серләре" түгәрәгенең максаты**: үз халкының рухи байлыгын өйрәнү, аны үстерү һәм саклау өчен үзләреннән өлеш кертүгә омтылыш тәрбияләү; укучыларда эзләнү-тикшеренү, материалны системага салу күнекмәләре формалаштыру; туган як белән кызыксынуларын үстерү һәм аңа мәхәббәт,туган ягыбыздан чыккан әдипләр, күренекле кешеләр белән кызыксыну һәм алар белән горурлану хисләре тәрбияләү.

Максатка ирешү өчен **түбәндәге бурычларны** хәл итү күздә тотыла:

*Уку – укыту:*

- туган як тарихын, әдәбиятын, сәнгатен, аларга бәйле шәхесләрне, мәгариф һәм сәнгать тарихын эзлекле өйрәнү;

- укучыларда эзләнү-тикшеренү, материалны системага салу күнекмәләре булдыруга ихтыяҗ тудыру;
- туган төбәгебез турында алган белемнәрне тирәнәйтү һәм камилләштерү.
- түгәрәк әгъзалары тарафыннан уңышлы дип табылган әсәрләрне республикада чыгып килә торган газета - журналга тәкъдим итү;

- *Тәрбияви:*
- укучыларда милли үзаң формалаштыру;
- туган төбәгебезгә мәхәббәт,туган ягыбыздан чыккан әдипләр, күренекле кешеләр белән кызыксыну һәм алар белән горурлану хисләре тәрбияләү.

- *Үстерелешле:*
- укучыларга үзләренең нәсел тамырларына, үз гаиләләренең үткәненә кызыксыну уяту;
- туган төбәгебезнең истәлекле урыннарына, җөмһүриятебезнең тарихи шәһәрләренә, табигатькә экскурсияләр үткәрү;
- мөстәкыйль рәвештә эзләнү – тикшеренү һәм иҗади эшләргә рухландыру.
- төрле бәйгеләрдә катнашу, укучыларның буш вакытларын файдалы итеп үткәрүгә ирешү.

## 2 нче бүлек
## Уку-укыту тематик планы
## Беренче уку елына укыту- тематик план

| № | Тема | Сәгать саны | | | Аттестация формасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Бар лы-гы | тео-рия | прак тика | |
| | ***I бүлек. Минем кечкенә Ватаным*** | | | | |
| 1 | **1.** “Туган як серләре” түгәрәгендә техника куркынычсызлыгы һәм үз – үзеңне тоту кагыйдәләре.<br>Үз нәселеңне беләсеңме?- гаилә тарихын өйрәнү | 2 | 2 | | |
| 2 | **2.** Минем кечкенә Ватаным | 2 | | 2 | |
| 3 | **3.** Туган ягымның табигате: үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы | 2 | | 2 | |
| 4 | **4.**Авылымның(шәһәрнең) исеме каян килеп чыккан**?** | 2 | | 2 | |
| 5 | **5.** Туган төбәгем халкы: көнкүреше һәм яшәеше. | 2 | | 2 | |
| 6 | **6.** Туган якта һөнәр ияләре | 2 | | 2 | |
| 7 | **7**. ***Минем гаиләм.*** Исемең матур, кемнәр куйган?(кичәгә әзерлек) | 2 | | 2 | |
| 8 | **8.** Исемең матур, кемнәр куйган?(кичә уздыру) | 2 | | 2 | “ Исемең матур, кемнәр куйган” |
| 9 | **9.** Гаиләмдә матур традицияләр | 2 | | 2 | |
| | ***II бүлек. Мәктәбем тарихы***<br>***(15 сәг.)*** | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 10 | **10**.Музей тарихы – визит карточкасы ясау | 2 | 2 | | |
| 11 | **11**.Музей өчен экскурсоводлар әзерләү | 2 | 2 | | |
| 12 | **12.**Үткәннәрдә безнең киләчәк (1918-1938 еллар) | 2 | | 2 | |
| 13 | **13**.Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый (1939-1945 еллар) | 2 | | 2 | |
| 14 | **14**.Мәктәбебез тәҗрибәле укытучылары белән горурлана (1946-1960) | 2 | | 2 | |
| 15 | **15**.Чал тарихлы мәктәбем (1960-1966) | 2 | | 2 | |
| 16 | **16.**Хәтерлим мин әле бүгенгедәй...(1967-1992) | 2 | | 2 | |
| 17 | **17**.Азнакай 1 нче урта мәктәбе – гимназиясе (1993-1998) | 2 | | 2 | |
| 18 | **18**.Шаулы мәктәп еллары (1999-2013) | 2 | | 2 | |
| 19 | **19.** Гасыр кичкән белем йорты (2014-бүгенге көн) | 2 | | 2 | |
| 20 | **20.** Мәктәп тарихы (Мәктәп музеендагы бүлекләр белән танышу) | 2 | | 2 | |
| 21 | **21.** Алар безнең мәктәптә укыдылар (Мәктәп музеендагы экспозиция белән танышу, өстәмә материаллар туплау) | 2 | | 2 | |
| 22 | **22.** Ветеран укытучыларның өйләрендә булу (очрашу) | 2 | | 2 | |
| 23 | **23.** Алар безнең мәктәптә укыдылар (Материаллар туплау, стенд төзү) | 2 | | 2 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 24 | **24.** Шушы яктан, шушы туфрактан без. Күренекле кешеләр белән очрашу үткәрү | 2 | | 2 | *Азнакайның күренекле кешеләре белән танышу* - ***“Бер күрешү-бер гомер”*** |
| | ***III бүлек. Чәчәкләр, гөлләр иле син, Азнакай!(20 сәгать)*** | | | | |
| 25 | **25.** Азнакай районы тарихы *битләреннән.*<br>*“Азнакай тамчылары”, “Азнакай” китаплары белән танышу* | 2 | | 2 | |
| 26 | **26.**Районның Туган як музеена экскурсия | 2 | | 2 | |
| 27 | **27.** Данлыклы райондашларыбыз. *Телдән журнал.* | 2 | | 2 | |
| 28 | **28.** Данлы Азнакаем минем... *Район үзәгендәге Җиңү паркына экскурсия.* | 2 | | 2 | |
| 29 | **29.**”*Маяк” газетасы редакциясенә экскурсия.* | 2 | | 2 | |
| 30 | **30.** Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый !(Бөек Җиңүнең 75 еллыгын каршылап...) | 2 | | 2 | |
| 31 | **31.** Геройлар аллеясы турында... | 2 | 2 | | |
| 32 | **32.** *Геройлар аллеясы буйлап... (экскурсия)* | 2 | | 2 | |
| 33 | **33.** Райондагы промышленность предприятиеләре | 2 | 2 | | |
| 34 | **34.** Районыбызның авыл хуҗалыгы | 2 | 2 | | |
| 35 | **35.** Азнакайның сәхнә йолдызлары – | 2 | 2 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | күренекле артистлар | | | | |
| 36 | **36.** Туган ягым  шагыйрьләре һәм язучылары | 2 | 2 | | |
| 37 | **37.**  Туган ягым язучылары | 2 | 2 | | |
| 38 | **38.** Азнакай төбәге җырчылары | 2 | 2 | | |
| 39 | **39.** “Якты йолдыз булып яна Азнакай күңелемдә”  - дәрес- конференция | 2 | 2 | | |
| 40 | **40.** *Әдәби – музыкаль кичәгә әзерлек “Шушы яктан, шушы туфрактан без”* | 2 | | 2 | |
| 41 | **41.** *Әдәби – музыкаль кичә “Шушы яктан, шушы туфрактан без”* | 2 | | 2 | ***Әдәби – музыкаль кичә “Шушы яктан, шушы туфрактан без”*** |
| 42 | **42.** Һөнәр сайлау – җаваплы эш. Туган төбәгебездә дәрәҗәле һөнәрләр (телдән журнал) | 2 | 2 | | |
| 43 | ***43.*** *“Дәрәҗәле һөнәр иясе Сез ,*<br>*Без дә Сездән үрнәк алабыз*”<br>(күренекле якташларыбыз - - мактаулы һөнәр ияләре) | 2 | | 2 | |
| 44 | **44.** Эзләнү – тикшеренү эшләре.<br>Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 | | 2 | |
| | **IV бүлек . Халкымның милли бизәкләрендә музейлар (12 сәг)** | | | | |
| 45 | **45**.Халкымның милли бәйрәмнәре һәм гореф-гадәтләре | 2 | | 2 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 46 | **46.**Сабантуй бәйрәме | 2 | | 2 | |
| 47 | **47**.Нәүрүз бәйрәме | 2 | | 2 | |
| 48 | **48**.Каз өмәсе йоласы | 2 | | 2 | |
| 49 | **49**.Кунаклашу, кич утыру йоласы | 2 | | 2 | |
| 50 | **50**.Халкымның күңел бизәкләре, Сөмбелә бәйрәме | 2 | | 2 | Халкымның күңел бизәкләре (кичә) |
| 51 | **51.**Бишек җырлары – тәрбиянең бик борынгы чарасы. Музейларда бирелеше | 2 | | 2 | |
| 52 | **52**.Кырык тартма - серле тартма, Күңелне үзенә тарта". Халык уеннары белән таныштыру өчен музей ихтыяҗы | 2 | | 2 | |
| 53 | **53.**Әкиятләр күргәзмәсе | 2 | | 2 | |
| 54 | **54**.Мәкаль һәм әйтемнәр – халык педагогикасының кыска һәм тирән мәгънәле әдәплелек кагыйдәләре. Музейдагы кулланылышы | 2 | | 2 | |
| 55 | **55."**Без-табигать баласы"  әкият-тамаша сәхнәләштерү | 2 | | 2 | |
| 56 | **56."**Без-табигать баласы"  әкият-тамаша сәхнәләштерү | 2 | | 2 | Без-табигать баласы" әкият-тамаша сәхнәләштерү |
| | ***V бүлек. Татарстан-минем республикам ( 16 сәгать)*** | | | | |
| 57 | **57**. ТР тарихы | 2 | 2 | | |
| 58 | **58.** Татарстанның символикасы | 2 | 2 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 59 | **59.** “И Казан! Серле Казан!” | 2 | 2 | | |
| 60 | **60.** Башкалабыз Казанга багышланган *“Йолдызлы сәгать” уены* | 2 | | 2 | |
| 61 | **61.** Күренекле шәхесләр: язучылар | 2 | 2 | | |
| 62 | **62.** Күренекле шәхесләр: шагыйрьләр | 2 | 2 | | |
| 63 | **63.** Күренекле шәхесләр: җырчылар | 2 | 2 | | |
| 64 | **64.** Күренекле шәхесләр: артистлар | 2 | 2 | | |
| 65 | **65.** Туган җирем – татар телле Татарстан (Туган тел турында...) | 2 | 2 | | |
| 66 | **66.** Туган төбәк, туган җир, туган телебез турында иҗади эшләр дәресе | 2 | | 2 | |
| 67 | **67.** “Газиз дә син, кадерле дә, әй Туган җирем!”- *“Тамчы-шоу” уены* | 2 | | 2 | **Интеллек-туаль бәйге** |
| 68 | **68.** Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 | | 2 | |
| 69 | **69**.Музейлар көнендә экскурсия | 2 | | 2 | |
| 70 | **70**.Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 | | 2 | |
| 71 | **71**.Түгәрәк эшенә еллык йомгак. Иң актив укучыларны билгеләү. Мактау кәгазьләре тапшыру | 2 | | 2 | |
| 72 | **72.** Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау. Йомгаклау. | 2 | | 2 | |
| **Барлыгы 144 сәг.** | | | | | |

## 2 уку елына укыту- тематик план

| № | Тема | Сәгать саны | | | Аттестация формасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | **Барлы-гы** | **тео-рия** | **практика** | |
| | ***I бүлек. Мин һәм минем гаиләм ( 18 сәгать)*** | | | | |
| 1 | **1.** “Туган як серләре” түгәрәгендә техника куркынычсызлыгы һәм үз – үзеңне тоту кагыйдәләре. | 2 | 2 | | |
| 2 | **2.** Хатлар ни сөйли? | 2 | | 2 | |
| 3 | **3.** Нәселем шәҗәрәсе | 2 | | 2 | |
| 4 | **4.** Нәселемнең укымышлы кешеләре. Нәселемнең озын гомерле кешеләре | 2 | | 2 | |
| 5 | **5.** Нәселем традицияләре | 2 | | 2 | |
| 6 | **6.** Нәселдәге кушаматлар | 2 | | 2 | |
| 7 | **7.** Нәсел агачын төзү үрнәкләре | 2 | | 2 | ***күргәзмә*** |
| 8 | **8**“Шәҗәрәдә гаиләм тарихы” | 2 | | 2 | |
| 9 | **9.** Нәсел агачын төзү (үз гаиләң үрнәгендә) | 2 | | 2 | |
| | ***II бүлек. Туган ягым – Азнакаем (50 сәгать)*** | | | | |
| 10 | **10.** Азнакаем тарихы | 2 | 2 | | |
| 11 | **11.** Азнакаемның исеме каян килеп чыккан? | | | | |
| 12 | **12.** Азнакай районы авыллары тарихы (Өлкән кешеләр белән очрашып язып алу), проект эше | 2 | | 2 | |
| 13 | **13.** Азнакай кешеләренең культурасы һәм көнкүреше(җырлар, бәетләр), проект эшен дәвам итү | 2 | | 2 | |
| 14 | **14.**Туган мәктәбем ветераннары. Ветеран укытучылар белән очрашу | 2 | | 2 | |
| 15 | **15.** Туган ягым һөнәрләре һәм һөнәрчеләре . Мәктәп музеена | 2 | | 2 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | экскурсия | | | | |
| 16 | **16.** Мәктәп музеена экскурсия | 2 | | 2 | |
| 17 | **17.** Туган ягымдагы хезмәт һәм хезмәт кешеләре ( төрле һөнәр ияләре белән очрашу). | 2 | | 2 | |
| 18 | **18.** Туган төбәк кешеләре Бөек Ватан сугышында (ветераннар турында презентация ясау) | 2 | | 2 | |
| 19 | **19.** 1 нче мәктәптә эшләгән һәм сугышта катнашкан ветераннар турында стенд. Материаллар туплау | 2 | | 2 | |
| 20 | **20**.Стенд өчен архив материаллары туплау. Эзләнү | 2 | | 2 | |
| 21 | **21.** Сугыш чоры балалары | 2 | | 2 | |
| 22 | **22.** Алар Ватан алдындагы бурычны үтәделәр (Әфганстанда хәрби хезмәттә булган Н.Бәдретдинов) | 2 | | 2 | |
| 23 | **23.** Мәктәп тарихы (Мәктәп музеендагы бүлекләр белән танышу) | 2 | | 2 | |
| 24 | **24.** Мәктәпнең элекке укытучылары (Мәктәп музеендагы экспозиция белән танышу, өстәмә материаллар туплау) | 2 | | 2 | |
| 25 | **25.** Ветеран укытучыларның өйләрендә булу (очрашу) | 2 | | 2 | |
| 26 | **26.** Алар безнең мәктәптә укыдылар (Материаллар туплау, стенд төзү) | 2 | | 2 | |
| 27 | **27.** Шушы яктан, шушы туфрактан без. Күренекле кешеләр белән очрашу үткәрү | 2 | | 2 | *М.Галиев белән очрашу (“Чатыртауд ан илһам алып)* |
| 28 | **28.** “Якты йолдыз булып яна Азнакай күңелемдә” - дәрес- конференция | 2 | | 2 | |
| 29 | **29.** Азнакайның тарихи урыннары.Телдән журнал | 2 | | 2 | |
| 30 | **30.** Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 | | 2 | |
| 31 | **31.** Район конкурс-бәйгеләрендә | 2 | | 2 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | катнашу өчен материаллар туплау | | | | |
| 32 | **32.** “Өч теләк” әкиятен сәхнәләштерүгә әзерлек, рольләргә бүлү | 2 | | 2 | |
| 33 | **33. “**Өч теләк” әкиятен сәхнәләштерү | 2 | | 2 | |
| 34 | **34**.“Өч теләк” әкиятен сәхнәләштерү | 2 | | 2 | Өч теләк” әкиятен сәхнәләштерү |
| | **III бүлек. Туган төбәгем әдәбияты (46 сәг)** | | | | |
| 35 | **35**. Илдус Гыйләҗев – җир шагыйре | | | | |
| 36 | **36**. Әдәби сәхифә “Илдус Гыйләҗев шигъриятенең өч таҗы” | 2 | | 2 | |
| 37 | **37**. Рөстәм Зәкуан “Җырым туса иде туган җирдә...” | 2 | | 2 | |
| 38 | **38**.Татар халкында яулыклар..... | 2 | 2 | | |
| 39 | **39**.“Ак яулыкны нигә ябалар?” (кичәгә әзерлек) | 2 | | 2 | |
| 40 | **40**.“Ак яулыкны нигә ябалар?” (кичә) | 2 | | 2 | |
| 41 | **41**.Марсель Галиев – Чатыр тау данын еракларга яңгыраткан якташ язучыбыз | 2 | | 2 | |
| 42 | **42**.Нур Әхмәдиев – шагыйрь һәм прозаик | 2 | | 2 | |
| 43 | **43**.Фәүзия Төхвәтуллина | 2 | | 2 | |
| 44 | **44.**Флёра Гыйззәтуллина шигырьләре – “тормышның үз авазы” | 2 | 2 | | |
| 45 | **45**.Резедә Шәрипова – яраткан шагыйрәбез | 2 | | 2 | |
| 46 | **46**.Әнәс Кари –кыска иҗат гомерен балалар әдәбиятына багышлаган шагыйрь | 2 | 2 | | |
| 47 | **47**.Галия Сәетшина – авылга дан җырлаучы якташыбыз | 2 | 2 | | |
| 48 | **48**.Сәрвәр Хәнипова – туган җирнең матурлыгына, аның халкына дан җырлаучы укытучы-шагыйрә | 2 | 2 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 49 | **49**.Илмира Сәлахова – балачак шагыйрәсе | 2 | 2 | | |
| 50 | **50**.Экскурсоводлар белән индивидуаль эш. | 2 | 2 | | |
| 51 | **51.**Әнәс Исхаков – чишмәләр моңы | 2 | | 2 | |
| 52 | **52**.Тәслимә Корбанова – көрәшче шагыйрә | 2 | | 2 | |
| 53 | **53.**Самат  Мирсәетов – Чатыр тау яклаучысы | 2 | | 2 | |
| 54 | **54**.Туган төбәгебез шагыйрь – язучылары турында проектлар төзү, яклау | 2 | | 2 | |
| 55 | **55**.“Без шигырь яратабыз” шигырьләр уку бәйгесе | 2 | | 2 | |
| 56 | **56**.Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 | | 2 | |
| 57 | **57**.“Өч кыз” әкиятен сәхнәләштерү | 2 | | 2 | |
| | ***IV бүлек. Татарстан-минем республикам ( 38 сәгать)*** | | | | |
| 58 | **58**. ТР тарихы | 2 | 2 | | |
| 59 | **59.** Татарстанның символикасы | 2 | 2 | | |
| 60 | **60.** ТРның географик урыны | 2 | 2 | | |
| 61 | **61.** Татарстанның табигате | 2 | 2 | | |
| 62 | **62.** ТР шәһәрләре.<br>Республика шәһәрләре белән таныштыру. | 2 | 2 | | |
| 63 | **63.** Тарихи шәһәрләргә читтән торып экскурсия ясау. | 2 | 2 | | |
| 64 | **64.** Казан-чал тарихлы башкала. | 2 | 2 | | |
| 65 | **65.** “И Казан! Серле Казан!” | 2 | 2 | | |
| 66 | **66.**  Башкалабыз Казанга багышланган *“Йолдызлы сәгать” уены* | 2 | | 2 | |
| 67 | **67.** Күренекле шәхесләр: язучылар | 2 | 2 | | |
| 68 | **68.** Күренекле шәхесләр: шагыйрьләр | 2 | 2 | | |
| 69 | **69.**  Күренекле шәхесләр: җырчылар | 2 | 2 | | |
| 70 | **70.** Күренекле шәхесләр: артистлар | 2 | 2 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 71 | **71.** Туган җирем – татар телле Татарстан (Туган тел турында...) | 2 | 2 | | |
| 72 | **72.** Туган төбәк, туган җир, туган телебез турында иҗади эшләр дәресе | 2 | | 2 | |
| 73 | **73.** “Татарстан һәм татар халкы тарихы” конкурсы | 2 | | 2 | |
| 74 | **74.** “Газиз дә син, кадерле дә, әй Туган җирем!”- *“Тамчы-шоу” уены* | 2 | | 2 | **Интеллек-туаль бәйге** |
| 75 | **75.** Эзләнү – тикшеренү эшләре | 2 | | 2 | |
| 75 | **76.** Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | 2 | | 2 | |
| ***V бүлек. Татар халкының бәйрәмнәре ( 30 сәгать)*** | | | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 77 | **77**.Татар халкының бәйрәмнәре | *2* | 2 | | |
| 78 | **78**.Дини бәйрәмнәр | *2* | 2 | | |
| 79 | **79**.Сабантуй- хезмәт туе | *2* | | *2* | |
| 80 | **80**.Ел фасылларына бәйле милли бәйрәмнәр, йолалар, гореф-гадәтләр | *2* | *2* | | |
| 81 | **81**.“Нәүрүз” бәйрәме | *2* | | *2* | |
| 82 | **82**.Милли киемнәр. Татар хатын-кызларының милли киеме. Ир-атларның милли киеме. Милли киемнәрнең бизәлеше, төсләре. | *2* | *2* | | |
| 83 | **83**.Кунаклашу йоласы | *2* | | *2* | |
| 84 | **84**.Җырлы –биюле уеннар | *2* | *2* | | |
| 85 | **85**.“Ефәк элдем читәнгә” (җырлы – биюле уены) | *2* | | *2* | |
| 86 | **86**.Исем йөртмәк- серле хикмәт” | *2* | | *2* | |
| 87 | **87**.“Аулак өй” уены | *2* | | *2* | |
| 88 | **88**.Чишмә буенда кичке уен | *2* | | *2* | |
| 89 | **89**.“Сөмбелә” бәйрәме | *2* | | *2* | |
| 90 | **90**.Әбиемнең сандыгында ниләр бар? | *2* | | *2* | |
| 91 | **91**.Табышмаклар кичәсе | *2* | | *2* | |
| ***VI бүлек. Шигырь язарга өйрәнәбез (8 сәгать)*** | | | | | |
| 92 | **92**.Шигырьдә ритм һәм рифма саклау кагыйдәләре | *2* | | *2* | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Күренекле шагыйрьләрнең шигырьләрен уку, шигырь төзелешен тикшерү. | | | | |
| 93 | **93**.Газета - журналларда басылган шигырьләргә күзәтү<br>Төрле темаларга шигырьләр иҗат итү, аларны утырышларда уку, анализлау, әдәби тәнкыйть ясау. | *2* | | *2* | |
| 94 | **94**.“Көмеш кыңгырау”, “Ялкын”, “Сәхнә” журналы белән танышу. Мәкалә язу | *2* | | *2* | ***Мәкалә язу*** |
| 95 | **95**.2021 нче ел Тукай премиясе лауреатлары | *2* | *2* | | |
| ***VII бүлек. Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый... ( 6 сәгать )*** | | | | | |
| 96 | **96**.Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый... (БВС ның 76 елллыгы ) – шәһәребезнең Җиңү паркына, Җиңү мәйданындагы мәңгелек ут монументына экскурсия | *2* | | *2* | |
| 97 | **97**.Экскурсоводлар белән индивидуаль эш. | *2* | | *2* | |
| 98 | **98.**“Үлемсез полк” акциясендә катнашуга әзерлек, катнашу | *2* | | *2* | |
| ***VIII бүлек. Газета-журнал укый беләбезме? (20 сәгать)*** | | | | | |
| 99 | **99.**Газета ничек ясала?<br>“МАЯК” газетасы редакциясенә экскурсия | *2* | | *2* | |
| 100 | **100**.Хәбәрчегә хас сыйфатлар<br>Минем яраткан газетам | *2* | *2* | | |
| 101 | **101**.Газета алдаганны яратмый.<br>Газеталарга күзәтүләр | *2* | | | |
| 102 | ***102**.Хәбәри жанрлар:*<br>Хәбәр язарга өйрәнәбез. Мәктәптә булган вакыйга яки факт турында язу | *2* | | *2* | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 103 | **103**.Репортаж-күзәтче жанр. Очрашулар, бәйрәмнәрдән репортажлар язу | *2* | | *2* | |
| 104 | ***104****.Аналитик жанрлар:* Корреспонденция- җәмәгатьчелек игътибарын проблемага юнәлтә | *2* | *2* | | |
| 105 | **105**.Мәкалә һәм аның төрләре: үтенеч, сорау, информация, бәяләмә, рәхмәт | *2* | *2* | | |
| 106 | **106**.Музейлар көненә видеоролик ясау | *2* | | *2* | |
| 107 | **107**.Музейга экскурсия | *2* | | *2* | |
| 108 | **108**.Түгәрәк эшенә еллык йомгак. Иң актив укучыларны билгеләү. Мактау кәгазьләре тапшыру | *2* | *2* | | |
| **Барлыгы 216 сәг.** | | | | | |

## Өченче уку елына укыту- тематик план

| № | Тема | Сәгать саны | | | Аттестация формасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Бар-лы-гы | Теория | Практика | |
| *I бүлек. Туган төбәгем әдәбияты ( 50 сәгать)* | | | | | |
| 1 | “Әдәби туган як” түгәрәгендә техника куркынычсызлыгы һәм үз – үзеңне тоту кагыйдәләре. | *2* | 2 | | |
| 2 | Илдус Гыйләҗев – җир шагыйре | *2* | | | |
| 3 | Әдәби сәхифә “Илдус Гыйләҗев шигъриятенең өч таҗы” | *2* | | *2* | |
| 4 | Рөстәм Зәкуан “Җырым туса иде туган җирдә...” | *2* | | *2* | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 5 | “Яулыклар сере....” (М.Галиев “Су буеннан әнкәй кайтып килә”...әниләр турында кичә) | *2* | | *2* | |
| 6 | “Ак яулыкны нигә ябалар?” (кызлар белән кичә) | *2* | | *2* | |
| 7 | Марсель Галиев – Чатыр тау данын еракларга яңгыраткан якташ язучыбыз. | *2* | | *2* | |
| 8 | “Марсель Галиев укулары”нда катнашу | *2* | | *2* | |
| 9 | Нур Әхмәдиев – шагыйрь һәм прозаик | *2* | | *2* | |
| 10 | Фәүзия Төхвәтуллина | *2* | | *2* | |
| 11 | Флёра Гыйззәтуллина шигырьләре – “тормышның үз авазы” | *2* | | *2* | |
| 12 | Резедә Шәрипова – яраткан шагыйрәбез | *2* | | 2 | |
| 13 | Әнәс Кари –кыска иҗат гомерен балалар әдәбиятына багышлаган шагыйрь | *2* | | | |
| 14 | Галия  Сәетшина – авылга дан җырлаучы якташыбыз | *2* | | *2* | |
| 15 | Сәрвәр Хәнипова – туган җирнең матурлыгына, аның халкына дан җырлаучы укытучы-шагыйрә | *2* | | *2* | |
| 16 | Илмира Сәлахова – балачак шагыйрәсе | *2* | | *2* | |
| 17 | Экскурсоводлар белән индивидуаль эш. | *2* | | *2* | |
| 18 | Туган төбәгебез шагыйрь – язучылары турында проектлар төзү, яклау | *2* | | *2* | |
| 19 | “Без шигырь яратабыз” шигырьләр уку бәйгесе | *2* | | *2* | |
| 20 | Район конкурс-бәйгеләрендә катнашу өчен материаллар туплау | *2* | | *2* | |
| 21 | Әнәс Исхаков иҗатына күзәтү | *2* | | *2* | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 22 | Тәслимә Корбанованың куен дәфтәреннән шигъри мизгелләр | *2* | | 2 | |
| 23 | Самат Мирсәетовның “Чатыртау” китабына күзәтү | *2* | | | |
| 24 | Туган төбәгебез шагыйрь-язучылары турында проектлар төзү, яклау | *2* | | *2* | |
| 25 | “Без шигырь яратабыз”. Туган як турында сәнгатьле шигырь уку бәйгесе | *2* | | *2* | |
| | ***II бүлек. Татар халкының бәйрәмнәре (30 сәгать)*** | | | | |
| 26 | Татар халкының бәйрәмнәре | *2* | | *2* | |
| 27 | Дини бәйрәмнәр | *2* | | *2* | |
| 28 | Сабантуй- хезмәт туе | *2* | | *2* | |
| 29 | Ел фасылларына бәйле милли бәйрәмнәр, йолалар, гореф-гадәтләр | *2* | | *2* | |
| 30 | “Сөмбелә” бәйрәме | *2* | | *2* | |
| 31 | “Нәүрүз” бәйрәме | *2* | | **2** | |
| 32 | Милли киемнәр. Татар хатын-кызларының милли киеме. Ир-атларның милли киеме. Милли киемнәрнең бизәлеше, төсләре. | *2* | | *2* | |
| 33 | Кунаклашу йоласы | *2* | | *2* | |
| 34 | Җырлы-биюле уеннар | *2* | | *2* | |
| 35 | “Ефәк элдем читәнгә” җырлы-биюле уены | *2* | | *2* | |
| 36 | “Исем йөртмәк-серле хикмәт” | *2* | | *2* | |
| 37 | “Аулак өй” | *2* | | *2* | |
| 38 | “Чишмә буенда кичке уен” | *2* | | *2* | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 39 | Табышмаклар кичәсе | *2* | | *2* | |
| 40 | Әбиемнең сандыгы | *2* | | *2* | |
| ***III бүлек. Туган ягым–Азнакаем ( 44 сәг)*** | | | | | |
| 41 | Азнакаем тарихы | *2* | | | |
| 42 | Азнакаемның исеме каян килеп чыккан? | *2* | *2* | | |
| 43 | Азнакай районы авылларында географик атамалар һәм аларның тарихы , проект эше | *2* | | *2* | |
| 44 | Проект эшен дәвам итү | *2* | | *2* | |
| 45 | Туган мәктәбемнең мөхтәрәм ветераннары белән очрашу, истәлекләр язып алу | *2* | | *2* | |
| 46 | Туган ягым һөнәрләре һәм һөнәрчеләре . Мәктәп музеена экскурсия. | *2* | | *2* | |
| 47 | Азнакай тарихы . Мәктәп музеена экскурсия. | *2* | | *2* | |
| 48 | Туган ягымдагы хезмәт һәм хезмәт кешеләре ( төрле һөнәр ияләре белән очрашу) | *2* | | *2* | |
| 49 | Туган төбәк кешеләре Бөек Ватан сугышында (ветераннар белән очрашу, өйләрендә булу) | *2* | | *2* | |
| 50 | Сугыш чоры балалары | *2* | *2* | | |
| 51 | Алар Ватан алдындагы бурычны үтәделәр (Әфганстанда хәрби хезмәттә булган Н.Бәдретдинов) | *2* | | *2* | |
| 52 | Мәктәп тарихы (Мәктәп музеендагы бүлекләр белән танышу) | *2* | | *2* | |
| 53 | Мәктәпнең элекке укытучылары (Мәктәп музеендагы экспозиция белән | *2* | | *2* | |

| | | | | | |
